КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 март г.Казань № 306

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 февраль, 110 нчы; 2018 ел, 7 май, 327 нче; 2018 ел, 30 июль, 614 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1288 нче; 2019 ел, 23 апрель, 329 нчы; 2019 ел, 18 декабрь, 1165 нче; 2020 ел, 11 февраль, 87 нче; 2020 ел, 15 май, 392 нче; 2020 ел, 8 август, 666 нчы; 2021 ел, 17 июнь, 467 нче; 2021 ел, 11 август, 700 нче; 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче; 2021 ел, 27 ноябрь, 1140 нчы; 2021 ел, 9 декабрь, 1209 нчы; 2022 ел, 7 март, 202 нче; 2022 ел, 17 март, 244 нче; 2022 ел, 29 апрель, 402 нче; 2022 ел, 22 сентябрь, 1029 нчы; 2022 ел, 11 ноябрь, 1196 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

$4.2.2^{1}$ пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

6.1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

6.2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

6.4.11 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

6.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.6. Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары законнар нигезендә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә физик көчне, махсус чараларны кулланырга, шулай ук хезмәт коралын һәм күрсәтелгән корал буларак рөхсәт ителгән саклану коралын һәм аучылык ату коралын «Корал турында» 1996 елның 13 декабрендәге 150-ФЗ номерлы Федераль законда, шулай ук «Ведомство сагы турында» 1999 елның 14 апрелендәге 77-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә кулланырга, сакларга һәм йөртергә хокуклы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин